**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

« 30 » октябрь, 2024 ел Түбән Суык-Су № 24

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге Советының 27.06.2019 елның 5/2 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «Нигезләмәне раслау хакында»

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы Дуслык, Юнусова, Молодежная, Набережная, Камышлы, Новая,Новая Полевая, Полевая, Строителей, Заречная, 8 Марта, Мазино урамнарында 2024 елның 15 ноябренә 13.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы Остров, Центральная, Школьная, Парковая, им.Г.Тукая, им.М.Ждалиля, Садовая, Солнечная, Татарстан, Тынычлык, Успешная, Цветочная, Яшьлек, 70 лет Победы, Дружбы, Радужная, Энтузиастов урамнарында 2024 елның 15 ноябренә 16.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Түбән Суык-Су авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен

киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, китерү, махсус техника хезмәте күрсәтү);

- урам яктырту эшләрен башкару (электр җиһазлары, комплектлау элементлары, урам яктырту баганалары һәм кабель сатып алу, китерү, урнаштыру, урам яктыртуны монтажлау);

- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү (бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту));

- торак пункт территориясен төзекләндерү(балалар мәйданчыгы өчен уен элементларын сатып алу, китерү, монтажлау);

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират территориясен төзекләндерү (агачларны кисү));

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын инвентарен сатып алу һәм урнаштыру (көпшә, җиңсә));

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре)

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Түбән Суык-Су авылы, Үзәк урам, 1А йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Нуруллин